**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.03.2020 № 185

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 6 мартындагы 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына исәпкә кую һәм күчерү" буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2019 елның 6 мартындагы 242 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктының 15 абзацын төшереп калдырырга;

16, 14 абзацларны 15, 16 абзацлар дип санарга;

1.2 пункттагы 13 пунктчадан "наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында" сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.6 пунктының икенче абзацын "Комплектлаштырганда системада балаларның яше агымдагы елның 1 сентябренә исәпләнә" дигән җөмләне төшереп калдырырга;

3.4.6 пунктының 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Буш урыннар булса, белем бирү оешмасына кабул итү календарь ел дәвамында гамәлгә ашырыла.";

"Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты" II бүлегендәге 2.8 пунктындагы таблицаның 2 графасында "Теләгән оешмадагы тәрбия һәм белем бирүне алып бару теленең теләккә туры килмәве" сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов